РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**14.05.2019** **г.Чистополь** **№ 68**

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
2016 елның 27 июнендә раслаган
«Стационар булмаган сәүдә
объектларының урнашу схемалары»
турындагы 96 нчы карарына
үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында”гы 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясына таянып, "Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибе турында” гы 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында"гы 2016 ел, 13 август, 553 нче карарына таянып, «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында " 2017 ел, 18 сентябрь, 675 нче карарына нигеләнеп, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы 2016 елның 27 июнендә 96 номеры белән расланган карары схемасына өстәмәләр кертергә, кушымта нигезендә 74-76 пунктларны өстәргә.

2. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре
Башкарма комитетының
2019 елның 14 маендагы
68 не карарына кушымта

Чистай муниципаль районы һәм Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/н | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты төре | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 74. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., 100 | азык-төлек товарлары | сәүдә павильоны | 6 | ел әйләнәсе |
| 75. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., 100 | азык-төлек булмаган товарлар | сәүдә павильоны | 13 | ел әйләнәсе |
| 76. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., 100 | азык-төлек товарлары | киоск | 2 | ел әйләнәсе |